## УЛ ЯРДӘМЧЕЛ КЕШЕ ИДЕ

Быел җәй күңелсез килде. Өзлексез яңгыр яуды, яңгыр яумаганда салкын җил исте. Шундый көннәрнең берсендә — июльнең дүртесендәме, бишесендәме, иртән иртүк торып, без хатын белән яңа аэропортка киттек. Көньякка барабыз. Кояшлы, диңгезле якка. Кесәдә билет та бар, путевка да.

Безнең белән бергә китәргә тиешле Марсель Галиев, хатыны Динә, кызы Зөлфия аэропортка бездән алдарак килеп җиткәннәр. Сибгат абыйның үлеме турында шунда — салкын, шыксыз аэровокзалда беренче булып Марсель Галиев әйтте.

Үлгән. Сибгат абый үлгән. Әле генә исән кеше турында «үлгән», «вафат» сүзе ишеткәч, мондый хәбәргә гадәттә ышанасы килми. «Юк, дөрес түгелдер! Дөньяда андый хәл булмый», дип әйтәсе килә. Ләкин Марсель Галиев бер дә шаяртып сөйләмәде. Күрәсең, дөрестер.

Шул чакны Сибгат абый белән соңгы очрашу, соңгы сөйләшүләр искә төште. Ул быел Мәскәүгә СССР Язучылар союзы съездына делегат булып барырга тиеш иде. Съездга мине дә сайлаганнар иде. Съезд, Мәскәү турында сүз чыккач ул: икебез бер бүлмәдә торырбыз дигән иде. Безгә аның белән бер бүлмәдә тору насыйп булмады. Без Мәскәүгә киткәндә ул Казанда, больницада ятып калды.

Без самолет көткән арада иртәнге почта килеп җитте, киоскта яңа газеталар сата башладылар. Ул көнне чыккан «Социалистик Татарстан»да Сибгат Хәкимнең кара сызыклар белән бүлеп алынган таныш рәсеме басылган иде.

Безгә, ниһаять, самолет «бирделәр». Без ашыгып, этешә-төртешә дигәндәй, биек, озын баскычтан самолетка мендек, йомшак урыннарга кереп утырдык. Күп тә үтмәде, җылы һәм рәхәт эзләп без каядыр Каф-тау артына китеп бардык. Моннан бер ай чамасы элек кенә Мәскәүгә киткән чактагы кебек, Сибгат абый тагын Казанда калды. Мәңгегә Казанда калды. Ләкин аның рухы һәрвакыт безнең белән бергә булды. Пицундада егерме дүрт көн буена ул стенадан, кара сызыклы газета кисәгеннән безгә карап елмаеп торды.

Әле кайчан гына синең белән бергә булган, синең белән ашап-эчеп, сөйләшеп йөргән кеше турында истәлек язу ничектер сәеррәк тә, уңайсыз да кебек. Бит Сибгат абыйны



белмәгән кеше юк! Аның турында нинди генә яңа сүз, мәгънәле сүз әйтермен икән?

Беренче мәртәбә мин аны 46 нчымы, 47 нчеме елда күрдем. Студент чагымда бик азапланып ниндидер оп-озын шигырь яздым да курка-курка гына «Совет әдәбияты» редакциясенә киттем. Шигырьне Сибгат Хәкимгә бирделәр. Әллә үзем бирдем микән соң?

Ул анда ниндидер бүлектә эшли иде бугай. Әле дә хәтеремдә: тәбәнәк буйлы, ыспай гәүдәле, ачык йөзле. Өстендә яшькелт китель. Яңа армиядән кайткан чагы булгандыр инде.

Икенче мәртәбә редакциягә баргач, минем озын шигырь турында Сибгат абый нидер сөйләде. Ни сөйләгәне инде онытылган, тик шунысы гына истә — шигырьне ул ошатмаган иде. Шуннан соң мин беркайчан шигырь язмадым, редакциягә шигырь алып бармадым. Минем шагыйрь булып китмәвемә Сибгат Хәким сәбәпче булды дип әйтәсем килми. Шагыйрь була алмавыма мин үзем сәбәпче. Тик шулай да аның тәнкыйте файдасыз булмагандыр дип уйлыйм. Шуннан соң мин күбрәк прозага игътибар итә башладым.

Күпмедер вакыттан соң шул ук «Совет әдәбияты» редакциясенә мин «Сезнеңчә ничек?» дип аталган беренче зур күләмле әсәремне күтәреп киттем. Романны укып чыктылар, мактадылар, ләкин басарга ашыкмадылар. Миңа әсәрнең кайбер җирләрен төзәтергә куштылар. Мин инде, күрәмсең, масаеп һәм киреләнеп, төзәтүдән баш тарттым. Проза секциясендәме, идарә утырышындамы өлкән абзыйлар мине һәм минем әсәрне тикшергәннәр. Башкалар белән бергә шунда Сибгат Хәким дә мине яклап чыккан. Шуннан соң мин аны бөтен күңелем белән якын күрә башладым.

«Бала күңеле далада» романы белән дә, башкалары белән дә минем эшләр шулайрак булды. Әсәрне, нигездә, ошаттылар, ләкин минем карашка, минем теләккә каршы килеп, һәрвакыт диярлек нәрсәсен дә булса сызып ташларга, нәрсәсен дә булса үзгәртеп язарга куштылар. Язылган әйберне алай җиңел генә үзгәртеп-төзәтеп булмый. Мин каршы килдем. Шунлыктан миңа еш кына редакция-нәшрият кешеләре белән тартышырга һәм яклау эзләп әле идарәгә, әле өлкән язучыларга сыгынырга туры килде. Мине яклаучыларның берсе һәрвакыт Сибгат, Хәким булды.

Мин белгән Сибгат Хәким гомумән яклаучы булды дисәм, һич тә хата булмас. Ул гомере буена яклаучы булды.

Ул изгелекне яманлыктан яклады һәм ярдәмгә мохтаҗ һәркемгә ярдәм кулы сузды. Бик күпләр аны чын күңелдән хөрмәт иттеләр. Кайчан һәм кайда гына очратма, аның янында һәрвакыт кеше булыр. Һәркем аңа үзенең берәр сүзен, фикерен, гозерен әйтергә тырыша. Ул беркемнән баш тартмый — яшьләр белән дә, өлкәннәр белән дә сөйләшергә сүзе, уртаклашырга фикере була.

60 нчы елларда, ахрысы, Сибгат Хәким Бауман районы халык судында халык утырышчысы булды. Шул елларда аның суд күренешләре, судлашу хәлләре турындагы шигырьләре басылды. Аның суд күренешләрен чагылдырган «күңелсез» шигырьләре ул елларда яңалык буларак укылды. Суд турындагы шигырьләре басылгангамы, әллә халык утырышчысы булгангамы, Сибгат абый янына төрле кыерсытылганнар һәм дөреслек эзләүчеләр килә башлады. Бер вакытны Язучылар союзында, нindидер утырыш барган бүлмәгә, Сибгат абыйны эзләп, кечерәк буйлы бер авыл карты — рус кешесе килеп керде. Сибгат абый, көттереп-нитеп тормыйча, шундук әлеге карт белән коридорга чыгып китте.

Әдәбият кешеләре белән генә түгел, сәнгать кешеләре белән дә ул якыннан аралашып яшәде. Шагыйрь сүзләренә җырлана торган һәм бүгенге көндә халыклашып киткән күп кенә җырлары аның композиторлар, җырчылар белән иҗади дуслык нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Бу хакта Сибгат абый үзе дә, башкалар да язып чыктылар инде. Мин үзем сәнгать кешеләре белән якыннан аралашам дип әйтә алмыйм. Ләкин Сара апа Садыйкова белән очрашкан саен диярлек аның авызыннан: «Сибгат шулай дип әйтте, Сибгат болай дип әйтте» кебегрәк сүзләрне ишетергә туры килгәли иде. Сибгат абый композиторларга, җырчыларга җыр текстлары тәкъдим итү, үз текстларына көй яздыру белән генә шөгыльләнмәде дип уйлыйм. Ул сәнгатебез үсешенә хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә, тәэсир итәргә тырышты һәм бу юнәлештә гамәли эшләр дә башкарды. Монда мин аның Вафирә Гыйззәтуллина, Марс Макаров, Тавил Хаҗиәхмәтов турындагы төпле, җитди мәкаләләрен искә төшерә алам.

Сәнгать кешеләренә ул турыдан-туры иҗатка катнашы булмаган мәсьәләләрдә дә, әйтик, тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуда да тарсынмыйча, авырсынмыйча булышлык күрсәтте. Мин аның талантлы җырчы Шамил Әхмәтҗановка квартира алуда ярдәм итүен беләм. Үләренә бер ел чамасы кала аның сәламәтлеге бик үк шәптән булмады. Шундый хәлендә дә ул башкалар турында кайгыртудан туктамады. Монда тагын бер-ике мисал китереп китәсе килә.



Шулай бервакыт безнең уртак танышыбыз, филармония артисткасы Хәмдүнә Тимергалиева турында бер хәбәр сөйләде. Әлеге танышыбыз Хәмдүнәне филармония директорының кабинетыннан чыгып килгәндә очраткан. «Директор бүлмәсеннән җылап чыкты, малайкаем!» диде безнең таныш, Хәмдүнәне кызганып. Туры сүзле булганы өчен Хәмдүнәне филармония хуҗалары яратып җиткермиләр икән. Менә ничә ел инде аны квартира бирми аптыраталар икән.

Бу турыда мин Сибгат абыйга сөйләдем, Хәмдүнәгә берәр ничек ярдәм итеп булмас микән дидем. Әлеге хәбәр Сибгат абыйга да тәэсир итте. Ул шундук тиешле җиргә, тиешле кешеләргә барып карарга булды. Беркадәр вакыттан соң Сибгат абыйдан миңа хат килеп төште. Барган ул тиешле җиргә, сөйләшкән тиешле кешеләр белән. Үзебез дә беләбез, мөмкинлек чыгу белән Хәмдүнәгә яңа квартира бирербез дигәннәр. Бер елдан соң мин бер танышым аша Хәмдүнәнең квартира хәлләрен белештем. Юк, беркем аңа берни бирмәгән. Бу вакытта инде Сибгат абый җир куенында ята иде.

Шулай итеп, башлаган эшен ул бу юлы азагына кадәр җиткерә алмады. Хәер, аның тагын бер эшләнмәгән эше калды. Ул талантлы артист Илдус Әхмәтҗанов турында зурлап язып чыгарга тиеш иде. «Тукайны яттан белә, берүзе Тукай концертын алып барды. Олы талант. Шулай да бездә аны күрмәмешкә салыналар — атказанган исеме дә юк»,— диде Сибгат абый бер очрашкач Илдус Әхмәтҗанов турында.

Менә шундый ярдәмчел, кешелекле һәм олы җанлы кеше иде ул Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким.

*16 декабрь, 1986 ел.*

Чыганак: Таныш өянкеләр : Сибгат Хәким турында истәлекләр / төз.: М. Вильданова-Хәкимова, Р. Хәкимов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1996. – 295 б.